КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 29 октябрь г.Казань № 970

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында яңа коронавирус йогышлы авыруы таралуны булдырмау чаралары турында» 2020 ел, 19 март, 208 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасында санитар-эпидемиологик хәлне һәм яңа коронавирус йогышлы авыруы таралу үзенчәлекләрен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында яңа коронавирус йогышлы авыруы таралуны булдырмау чаралары турында» 2020 ел, 19 март, 208 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 15 август, 687 нче, 2020 ел, 2 сентябрь, 774 нче, 2020 ел, 18 сентябрь, 847 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 пунктта:

өченче абзацта «таксины да кертеп,» сүзләреннән соң «шулай ук Россия Федерациясе Баш дәүләт санитар табибының «Көчле сулыш юллары вирус инфекцияләре һәм грипп белән авыручылар санының сезонлы күтәрелүе чорында COVID-19 таралу куркынычын киметү буенча өстәмә чаралар турында» 2020 елның 16 октябрендәге 31 номерлы карары белән билгеләнгән башка урыннарда,» сүзләрен өстәргә»;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«2020 елның 31 октябреннән башлап 23.00 сәгатьтән 6.00 сәгатькә кадәр оешмалар һәм шәхси эшмәкәрләр тарафыннан тамаша-күңел ачу чаралары үткәрү;

2020 елның 31 октябреннән башлап 23.00 сәгатьтән 6.00 сәгатькә кадәр җәмәгать туклануы хезмәте күрсәтү, гражданнар тарафыннан җәмәгать туклануы объектлары биналарына кермичә, алып чыгып хезмәт күрсәтүдән, заказлар китереп бирүдән, аэропортлар, вокзаллар территорияләрендә җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәтүдән тыш.».

2. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин